**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

31.05.2018 № 385

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм норматив хокук актларына экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кую максатыннан, “Татарстан Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актларына экспертиза ясау тәртибе турында” 2014 елның 7мартындагы 14-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә һәм муниципаль идарә итүнең процессларын җайга салучы карарлар әзерләү һәм кабул итү өлешендә нәтиҗәлелеген күтәрү һәм камилләштерү максатында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм норматив хокук актларына экспертиза үткәрү тәртибен расларга.
2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеген җайга салу йогынтысын бәяләү өлкәсендә Вәкаләтле оешма итеп билгеләргә.
3. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.С. Әхмәтшин

ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының

2018 ел, 31 май, 385 номерлы карарына 1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм норматив хокук актларына экспертиза үткәрү Тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Бу Тәртип Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы норматив хокук актлары проектларының (алга таба – норматив хокук актлары проектлары) җайга салу йогынтысын бәяләү үткәрүгә бәйле булган мөнәсәбәтләрне җайга сала һәм эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагыла торган башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларына (алга таба – норматив хокук актлары) экспертиза ясау тәртибен билгели.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы норматив хокук актлары проектларының (алга таба – норматив хокук актлары проектлары) җайга салу йогынтысын бәяләү эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен кирәгеннән артык чыгымнар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетының нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә этәрә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.

Җайга салу йогынтысын бәяләү Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәсе (алга таба – Профильле бүлекчә) тарафыннан башкарыла.

Җайга салу йогынтысын бәяләү өлкәсендә Вәкаләтле бүлекчә булып Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге санала. Әлеге вәкаләтләргә ия оешма актларның проектларын методик һәм норматив яктан бәяләүне һәм норматив хокук актларына экспертиза ясау тәртибен тәэмин итә.

Җирле үзидарә органнары тарафыннан эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, норматив хокук актларына экспертиза ясау “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кую максатыннан, “Татарстан

Республикасы норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокук актларына экспертиза ясау тәртибе турында” 2014 елның 7 мартындагы 14-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, "ТР җирле үзидарә турында"законына үзгәрешләр кертү хакында” 2014 елның 10 маендагы № 30-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан кабул ителүче (чыгарылучы) Татарстан Республикасында гамәлдә булган норматив хокук актларының һәм норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын ачык бәяләү тәртибен раслау турында” 2012 елның 31 декабрендәге № 1182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары һәм башка хокук норматив актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.2. Эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлегенә кагылышлы түбәндәге мәсьәләләрнең проект актлары җайга салу йогынтысы буенча бәяләү узарга тиеш:

1.2.1.халыкка транспорт хезмәте күрсәтүдә һәм җирлек чикләрендә транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча шартлар тудыру;

1.2.2. халыкны элемтә хезмәте белән, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;

1.2.3.ял итү өчен шартлар, җирлектә мәдәният хезмәте күрсәтү өчен мөмкинлекләр тудыру;

1.2.4.җирлектә җирле халык сәнгате, иҗаты үсеше өчен шартлар тудыру, халык сәнгатен кабат торгызуда, үстерүдә катнашу;

1.2.5. авыл хуҗалыгы үсешенә ярдәм күрсәтү, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү;

1.2 эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа яки элегрәк каралган муниципаль норматив хокук акты нигезендә үзгәрүче вазыйфаларны билгеләү.

1.3. Актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, уйлап табучы тарафыннан хәзерләнгән акт проектындагы нигезләмәләрнең җайга салу йогынтысы дәрәҗәсен исәпкә алып үткәрелә:

1) җайга салу йогынтысының югары дәрәҗәсе - акт проектында эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә закон тарафыннан моңарчы билгеләнмәгән вазыйфалар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләр, шулай ук эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлегендә физик һәм юридик затлар өчен элек законнарда каралмаган чыгымнар барлыкка килүгә китерә торган нигезләмәләр урын ала;

2) җайга салу йогынтысының уртача дәрәҗәсе - акт проектында эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә закон тарафыннан элегрәк билгеләнгән вазыйфалар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган

нигезләмәләрне үзгәртүче, шулай ук эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлегендә физик һәм юридик затлар өчен элегрәк законнарда каралган чыгымнарны арттыруга китерә торган нигезләмәләр урын ала;

3) җайга салу йогынтысының түбән дәрәҗәсе – акт проектында беренче һәм икенче пунктта аталган нигезләмәләр төшеп кала, шулай да әлеге нигезләмә нигезендә җайлау йогынтысы ягыннан бәяләү үткәрелә.

Түбәндәге муниципаль акт төрләренә карата җайга салу йогынтысы ягыннан бәяләү башкарылмый:

-дәүләт сере саклаган яисә яшерен характердагы мәгълүмат тупланган актларга;

- муниципаль норматив хокук актларын федераль һәм региональ законнар белән билгеләнгән халәткә китерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелгән актларга;

-гадәттән тыш хәл булу ихтималын кисәтү яисә табигый һәм техноген төрдәге бәла-каазаны, кризис хәлләрне һәм террорчылык очракларын булдырмый калуны яки алар китергән зыянны юк итү максатындагы актларга;

-бюджетны раслау һәм аның үтәлеше хисабына юнәлдерелгән актларга;

- җирле салымнар һәм җыемнарны билгели, үзгәртә һәм гамәлдән чыгара торган актларга;

- муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар билгели торган, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр башкарган эшләр турындагы актларга;

- “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2013 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 нче маддәсе нигезендә кабул ителгән җәмәгать тыңлаулары йомгаклары һәм иҗтимагый фикер алышулар буенча актларга.

1.4. Норматив хокук актларына экспертиза экспертиза вәкаләтле оешма тарафыннан еллык план нигезендә уздырыла.

1.5. Норматив хокук актларына экспертиза уздыру өчен нигез булып район башкарма комитеты җитәкчесе йөкләмә яки күрсәтмәсе, эшмәкәрлек, инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә иҗтимагый оешмалар тәкъдимнәре, кулланучылар берләшмәләре, мөстәкыйль оешмалар, фәнни-эксперт оешмалары, җирле үзидарә органнары, эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлегендә профильле бүлекләр тарафыннан ачыкланасы мәсьәләләр табылганда, шул исәптән:

1) норматив хокук актларын мониторинглаштыру, шулай ук муниципаль максатчан программаларны мониторинглаштыру нәтиҗәсендә;

2) муниципаль җирлекнең иҗтимагый-икътисадый торышын мониторинглаштыру нәтиҗәсендә;

3) җирле үзидарә органнарына эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлегендә ачыкланасы мәсьәләләр булуы хакында гражданнар һәм оешмаларның күп тапкыр кабатланган мөрәҗәгате нәтиҗәсендә.

1.6. Экспертиза түбәндәге актларга карата уздырыла:

1) проектларга бәяләү үткәргәндә җайга салу йогынтысы югары дәрәҗәдә билгеләнгән һәм алар үз көченә кергәннән соң, ким дигәндә 3 ел узган, норматив хокук актлары;

2) акт проектлары әзерләнү стадиясендә җайга салу йогынтысы бәяләвен узмаган, һәм алар үз көченә кергәннән соң кимендә 1 ел узган, норматив хокук актлары, дәүләт хакимияте органнарыннан аларга экспертиза үткәрү турында алынган нигезле тәкъдимнәр, эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектларының мәнфәгатьләрен яклау максаты булган җирле үзидарә органнары, эксперт оешмалары, оешмалар йогынтысын бәяләүне үткәрү турында алар белән хезмәттәшлек килешүләр төзелгән башка затлар катнашындагы актлар.

Дәүләт сере сакланган яисә яшерен характердагы мәгълүмат тупланган, муниципаль норматив хокук актларына федераль һәм региональ законнар белән билгеләнгән халәткә китерүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелгән, гадәттән тыш хәл булу ихтималын кисәтү яисә табигый һәм техноген төрдәге бәла-каазаны, кризис хәлләрне һәм террорчылык очракларын булдырмый калуны яки алар китергән зыянны юк итү максатындагы актларга, бюджетларны раслау һәм аларның үтәлеше хисапларына юнәлдерелгән, җирле салымнар һәм җыемнарны билгели, үзгәртә һәм бетерә торган, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар билгели торган, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр башкарган эшләр турындагы актларга, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2013 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 нче маддәсе нигезендә кабул ителгән җәмәгать тыңлаулары йомгаклары һәм иҗтимагый фикер алышулар буенча актларга экспертиза үткәрелми.

1.7. Актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы норматив хокук актларына экспертиза уздыруның элемтә - коммуникацион Интернет челтәрендә рәсми сайты булып Нурлат муниципаль районы сайты санала.

## 2. Муниципаль норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру

2.1. Акт проекларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру этаплары түбәндәгеләр:

1)акт проектын һәм җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру өчен җыелма хисапны профильле бүлекчәгә җибәрү;

1)акт проекты һәм җыелма хисап буенча җәмәгать киңәшмәсе уздыру;

2)норматив хокук  акты проектының җайга салу йогынтысын бәяләү турында бәяләмә әзерләү;
3)әлеге бәяләмәне проектны эшләүчегә җибәрү.
2.2.Вәкаләтле орган тарафыннан җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру тәртибе раслана.
2.3.Җыелма хисап түбәндәге мәгълүматны үз эченә алырга тиеш:
1) норматив хокук акты  проектының җайга салу  йогынтысы дәрәҗәсен;
2) проблемалар тасвирламасы, муниципаль җайга салу юнәлдерелгән хәл, аның сәбәпләре, динамикасы һәм проблемаларның вакыт аралыгында үсешен фаразлауны;
3) хәзерге вакытта муниципаль җайга салу гамәлгә ашырылучы норматив хокук актлары яки аларның аерым нигезләмәләре;
4) проблеманы хәл итүнең вариантлары (тискәре йогынтысын киметү), шул исәптән, хокук куллану практикасын камилләштерү юлы белән, шулай ук норматив хокук актларын эшләү, үзгәртү яки гамәлдән чыгару;
5) муниципаль җайга салу максатларын;
6) муниципаль җайга салу юнәлдерелгән эшмәкәрлек һәм инвестицион эшчәнлек субъектлары  төркеменә характеристиканы;
7)  җирле үзидарә органнарының яңа функцияләрен, вәкаләтләрен, бурычларын һәм хокукларын яки  аларның үзгәрүе турында мәгълүматларны, шулай ук аларны гамәлгә ашыру тәртибен;
8) муниципаль бюджетның чыгымнарын бәяләү (мөмкин булган кертемнәрен),  эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының билгеләнгән бурычларны үтәү зарурлыгына  йә  мондый бурычларның эчтәлеге үзгәрүгә бәйле булган чыгымнарын бәяләүне;
9) муниципаль җайга салуның максатларга ирешү мониторингы индикаторлары (күрсәткечләре),  ачыкланган проблемаларның торышын чагылдыручы, җайга салу өлкәсендә проблемаларны анализлау вакытына әлеге индикаторларның әһәмияте һәм  индикатор дәрәҗәләре турындагы белешмә чыганакларын;
10)  акт проектының файдасы һәм чыгымнары турында тәфсилле тасвирламасын:  йогынты ясалачак иҗтимагый төркемнәр, икътисади секторлар, территорияләр; көтелгән тискәре һәм уңай йогынтысы, тиешле йогынтының сыйфатлы тасвирламасы әгәр мөмкин икән, аның микъдары буенча бәяләү, шулай ук тиешле йогынты ясау чоры (кыска, уртача, озак вакытлы);
11) норматив хокук актын кабул итү белән бәйле булган куркынычлылык һәм чыгымнарны бәяләүне;

12) норматив хокук акты кабул итү белән бәйле көтелгән нәтиҗәләр, югалтулар мөмкинлеге һәм чикләүләрне;

13) акт проектының үз көченә керүе күздә тотыла торган датаны;

14) җайга салу максатына ирешүнең сайлап алынган ысулы нәтиҗәле булу-булмауны контрольдә тоту методларын тасвирлауны;

15) җайга салуның игълан ителгән максатларына ирешү өчен кирәкле оештыру техник, методологик, мәгълүмати һәм башка чараларны;

16) хәбәрнамәне урнаштыру, тәкъдимнәр кертү вакытлары һәм аларны карауның гомумиләштерелгән нәтиҗәләре турында мәгълүматларны;

17) эшләүче фикере буенча тәкъдим ителә торган җайга салуның нигезле булуын бәяләргә мөмкинлек бирә торган башка мәгълүматларны.

Җыелма хисап Вәкаләтле орган раслаган форма буенча тутырыла.

## 3. Муниципаль норматив хокук актлары проектлары буенча ачык консультацияләр үткәрү

3.1.Ачык консультацияләр үткәрү норматив хокук акты проектын һәм җыелма хисапны җайга салу органы тарафыннан рәсми сайтта урнаштыру белән бер үк вакытта башлана.

3.2. Хәбәрнамәгә җайга салу органы җитәкчесе (яки аның урынбасары) кул куя һәм түбәндәге мәгълүмат күрсәтелә:

1)норматив хокук актының төре, исеме һәм үз көченә керер дип планлаштырыла торган вакыты;

2)җайга салу органы биргән хәбәрнамә нигезендә тәкъдимнәр кабул итүне гамәлгә ашырачак вакыт, аларны кертү өчен аеруча уңайлы ысул.

3.3. Җайга салу органы, тикшерү нәтиҗәләре буенча бу вакыт аралыгында килгән барлык тәкъдимнәрне карарга, билгеләнгән тәртиптә тәкъдимнәрнең тупланмасын төзергә тиеш.

3.4. Норматив хокукый акт проектлары буенча ачык консультацияләр үткәрү вакыты:

- җайга салу йогынтысы түбән дәрәҗәдә – 10 календарь көн;
- җайга салу йогынтысы уртача дәрәҗәдә – 20 календарь көн;
- җайга салу йогынтысы югары дәрәҗәдә – 30 календарь көн тәшкил итә.

3.5.Ачык консультацияләр үткәрүнең максаты булып:

1) норматив хокук акты проектының максаты нәтиҗәле булуын раслау, максатка ирешү өчен киткән вакытның файдалы, ә ирешелгән нәтиҗәләрнең югары дәрәҗәдә икәнлеген күрсәтү;

2) норматив хокук акты проектларында эшмәкәрлек, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен кирәгеннән артык бурычлар, тыюлар, чикләүләр һәм чыгымнар

барлыкка китерә яки аларны кертүгә ярдәм итә торган нигезләмәләр булу турында нәтиҗәләр чыгару;

3) норматив хокукый акт проектларында эшмәкәрлек, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен бюджет чыгымнары барлыкка китерә яки аларны кертүгә ярдәм итә торган нигезләмәләр булу турында нәтиҗәләр чыгару;

4) акт проектының эшмәкәрлек, инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен генә түгел, җәмгыять өчен дә файдалы якларын һәм чыгымнарын бәяләүне, шулай ук максатларга ирешүгә комачаулый алырдай авырлыкларны тәгаенләү;

5) норматив хокукый актлар кертүнең төрле вакытка караган нәтиҗәлелеген бәяли.

3.6. Ачык консультацияләр үткәрү нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләнә, ул үз чиратында үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

1) ачык консультацияләр нәтиҗәләре турында тулыландырылган бәяләмәне;

2) акт проектына кагылышлы тәкъдимнәр тупланмасын.

3.7 Әлеге бәяләмә Вәкаләтле орган җитәкчесе яки урынбасары тарафыннан имзаланып, өч көн эчендә рәсми сайтта бастырылып чыгарыла.

## 4. Норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү нәтиҗәләрен куллану тәртибе

4.1. Муниципаль норматив хокук актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү турында Бәяләмәсе һәм ачык консультацияләрдә катнашучылардан кергән тәкъдимнәр тупланмасы, ачык консультацияләр тәмамланудан соң 10 календарь көн эчендә, әлеге проектны эшләүчегә һәм Вәкаләтле вәкилгә җибәрелә.

4.2. Ачык консультацияләр үткәрү нәтиҗәләре буенча, акт проектында әлеге нигезләмәнең 1 нче пунктында күрсәтелгән нигезләр ачыклану очрагында, проект авторы әлеге проектны әзерләүдән яки җиренә җиткереп эшләп бетерүдән баш тарта.

Проект авторы, әлеге проектны әзерләүдән яки җиренә җиткереп эшләп бетерүдән баш тарткан очракта, җайга салу йогынтысы бәяләмәсен һәм тәкъдимнәр тупланмасын кулга алу белән унбиш календарь көннән дә соңга калмыйча, рәсми сайтта тиешле мәгълүматны бастыра.

Ачык консультацияләр үткәрү нәтиҗәләре буенча, акт проектында әлеге нигезләмәнең 1 нче пунктында күрсәтелгән нигезләр ачыкланмау очрагында, проект авторы проектны соңгы редакциясендә бастырып чыгара. Шулай ук ачык консультацияләр тәмамланудан соң 10 календарь көн эчендә кабул ителгән тәкъдимнәр тупланмасына кермичә калган тәкъдимнәр, кире кагу сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

4.3. Муниципаль норматив хокук акты проектының җайга салу йогынтысын бәяләү турында Бәяләмәсен алганнан соң 20 календарь көн эчендә кулланылмаган тәкъдимнәр, кире кагу сәбәпләре турында мәгълүмат бирелә.

4.4.Вәкаләтле орган тарафыннан проектның соңгы редакциясе, кулланылмаган тәкъдимнәр, кире кагу сәбәпләре турында мәгълүмат, муниципаль норматив хокук акты проектының җайга салу йогынтысын бәяләү турында Бәяләмәсен, тәкъдимнәр тупланмасы копиясен 5 көн эчендә рәсми рәвештә бастырып чыгара.

## 5.Норматив хокук актларына экспертиза үткәрү

5.1.Норматив хокук актларына экспертиза үткәрү түбәндәге этаплардан тора:

1) норматив хокук актларына экспертиза үткәрү өчен план төзү;

2) норматив хокук актларына экспертиза үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә проектларын әзерләү;

3) норматив хокук актларына үткәрелгән экспертиза нәтиҗәләре турында ачык консультацияләр үткәрү;

4) муниципаль норматив актлар проектларының экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү.

5.2. Муниципаль норматив актлар проектларына экспертиза үткәрү тәртибе Вәкаләтле бүлекчә тарафыннан раслана.

5.3. Муниципаль норматив актлар проектларына, Вәкаләтле бүлекчә тарафыннан алдан расланган План нигезендә, экспертиза уздырыла.

## 6. Норматив хокук актларына экспертиза үткәрүнең планын әзерләү

6.1.Планда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) норматив хокук актының исеме, реквизитлары;

2) хокукый актны эшләүче җайга салу органы, бүлекчәсе исеме;

3) норматив хокукый актка экспертиза үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмәне хәзерләү вакыты;

4) норматив хокукый актка экспертиза һәм ачык консультацияләр үткәрү вакыты.

6.2. Агымдагы ел тәмамлануга 4 айдан да соңга калмыйча, План формалаштыру максатыннан рәсми сайтта, Вәкаләтле бүлекчә тәкъдимнәр җыю турында хәбәр бирә.

6.3.Хәбәрнамә урнаштырылган көннән соң тәкъдимнәр 45 көн эчендә җыела.

6.4.Тәкъдимнәр җыелганнан соң 5 көн эчендә, Вәкаләтле бүлекчә тарафыннан Планга кертү һәм ачык консультацияләр уздыру өчен җыелган тәкъдимнәр тупланмасы рәсми сайтта бастырыла.

6.5.Тупланган тәкъдимнәр буенча ачык консультацияләр 30 календарь көн эчендә үткәрелә.

6.6. Ачык консультацияләр нәтиҗәләре нигезендә Вәкаләтле бүлекчә тарафыннан киләсе елга План формалаштырыла һәм раслана.

Расланган көннән соң 5 көн эчендә рәсми сайтта бастырылып чыгарыла.

## 7. **Норматив хокук актларына экспертиза үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм аның буенча ачык консультацияләр үткәрү**

7.1. Норматив хокук актларына экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмәгә һәм аның проектына түбәндәге белешмәләр керә:

1) Норматив хокук актының төп реквизитлары;

2) вәкаләтләренә иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең тикшереләсе өлкәсе караган норматив хокук актны кабул иткән оешма исеме;

3) акт проектына җайга салу йогынтысы бәяләвен уздыру нәтиҗәләре турында мәгълүмат ( уздыру очрагында);

4) норматив хокук актларының һәм аның аерым нигезләмәләренең гамәлдә булу вакыты;

5) норматив хокукый акт нигезендә билгеләнгән җайга салу нәтиҗәсендә мәнфәгатьләре кагылучы затлар даирәсе;

6) җайга салу хисабына проблемаларны һәм аның белән бәйле тискәре нәтиҗәләрне җиңүнең дәрәҗәсен бәяләү;

7) әлеге норматив хокукый актны гамәлгә ашыруның керемнәре һәм чыгымнарын бәяләү;

8) җайга салуның фактгагы уңай һәм тискәре нәтиҗәләрен бәяләү;

9) билгеләнгән җайга салу хисабына игълан ителгән максатларга ирешүнең нәтиҗәлелеген бәяләү;

10) эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге һәм башка төрдәге эшчәнлекне алып баруга нигезсез комачаулый торган нигезләмәләр булу хакында белешмә;

11) эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлегенә һәм җайга салу нәтиҗәлелеген арттыруга нигезсез комачаулый торган нигезләмәләрне юкка чыгару ысуллары турында тәкъдимнәр;

12) җайга салуның фактгагы йогынтысын бәяләргә мөмкинлек бирүче башка мәгълүматлар.

7.2. Профильле бүлекчә белән берлектә, норматив хокук актларына экспертиза үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә проекты хәзерләнә һәм Вәкаләтле бүлекчәгә юллана.

7.3. Ачык консультацияләргә, планда каралган вакытта, Вәкаләтле бүлекчә тарафыннан норматив-хокукый актларга экспертиза үткәрүнең нәтиҗәләре турында бәяләмә проекты чыгарыла.

Норматив-хокукый актларга экспертиза үткәрүнең нәтиҗәләре буенча бәяләмә проекты нигезендә ачык консультацияләр үткәрелү турында Вәкаләтле бүлекчә Нурлат муниципаль районы рәсми сайтында хәбәрнамә урнаштыра, экспертиза үткәрелүче норматив хокукый акт, экспертиза нәтиҗәләре турында бәяләмәнең проекты теркәлә.

7.4. Ачык консультацияләрнең үткәрелү вакыты, катнашучыларның үз фикерләрен юллау ысулы шулай ук бу хәбәрнамәдә күрсәтелә.

7.5. Норматив-хокукый актларга экспертиза үткәрүнең нәтиҗәләре буенча бәяләмә проекты нигезендә ачык консультацияләр үткәрелү вакыты 20 көннән азрак һәм 30 көннән күбрәк булалмый.

7.6. Вәкаләтле бүлекчә ачык консультацияләр нәтиҗәсендә тупланган барлык тәкъдимнәрне карап чыгарга һәм тәкъдимнәрне исәпкә алу яки кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, тәкъдимнәр тупланмасын төзергә тиеш.

Вәкаләтле бүлекчә тарафыннан норматив-хокукый актларга экспертиза үткәрүнең нәтиҗәләре турында бәяләмә проекты нигезендә үткәрелгән ачык консультацияләр буенча норматив-хокукый актларга экспертиза үткәрүнең нәтиҗәләре буенча бәяләмә төзелә.

7.7. Норматив-хокукый актларга экспертиза үткәрүнең нәтиҗәләре буенча бәяләмә Вәкаләтле бүлекчә җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм сайтта 5 эш көненнән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла.

## 8. Экспертиза нәтиҗәләрен куллану тәртибе

8.1. Норматив-хокукый актларга экспертиза үткәрүнең нәтиҗәләре буенча бәяләмә муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертүгә яки гамәлдән чыгаруга нигез булып тора.

8.2. Бәяләмә, кул куелганнан соң 10 көн эчендә Профильле бүлекчәгә җибәрелә. Вәкаләтле бүлекчә экспертиза нәтиҗәләре буенча район башлыгы (Башкарма комитет җитәкчесе) адресына муниципаль норматив актларга үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр җибәрергә хокуклы.